**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.10.2022 Балык Бистәсе штп. № 286пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 15.12.2021 ел, № 271 пи карары белән расланган ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 15.08.2022 ел, №1415 карарының 1 пунктындагы а пунктчасы нигезендә, муниципаль норматив хокукый актларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 15.12.2022 ел, №271пи карары белән расланган ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба-Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Регламентларның 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын киләсе редакциядә бәян итәргә:

"Формалаштырылган запросны формат - логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең һәрбер соратып алу формасындагы юлларны тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Әгәр бердәм портал электрон форманың дөрес тутырылмаган юлларын ачыкласа, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны төзәтү тәртибе сорауның электрон формасында мәгълүмати хәбәр юлы белән хәбәр ителә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасары А.А. Хәкимуллинга йөкләргә.

Җитәкче Р. Р. Ислямов